РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МИЧАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422055, Республика Татарстан, Сабинский район,
Село Старый Мичан , ул. Школьная , 12
тел. (84362) 42-3-31

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МИЧЭН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422055, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Иске Мичэн авылы., Мэктэп урамы, 12 йорт
тел. (84362) 42-3-31

e-mail: mich.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
16.10.2023г.

КАРАР
№ 19

Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Башкарма комитетының 02.03.2016 елгы № 12 карары белән расланган Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Башкарма комитетының гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм вазыйфаи затларның шәхси кабул итү Тәртибенә үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Башкарма комитетының 02.03.2016 елгы №12 карары белән расланган «Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Башкарма комитетының гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү Тәртибен раслау турында» гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Башкарма комитеты вазыйфаи затларының шәхси кабул итү Тәртибенә түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. 2.1. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Гражданның мөрәҗәгате (алга таба - мөрәҗәгать) - җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка язма рәвештә яки электрон документ рәвешендә, шул исәптән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланып (алга таба - Бердәм портал), тәкъдим, гариза яки шикаять, шулай ук гражданның җирле үзидарә органына телдән мөрәҗәгать итүе.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль

районы Мичән авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/michan адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Мичән авыл
җирлеге Башлыгы А.Ә.Гәрәев